ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2018 Казан ш. № 7-12/т

Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча пассажирларны һәм багажны гомуми файдаланудагы транспорт белән даими ташуларга чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү турында

«Автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законны тормышка ашыру хакында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча пассажирларны һәм багажны гомуми файдаланудагы транспорт белән даими ташуларга чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә, түбәндәгеләрне дә кертеп:

1.1. әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында ташулар;

1.2. әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, метрополитен белән ташулар.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан шәһәрендә җәмәгать транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларга чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү хакында» 25.03.2016 № 7-4/т номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.12.2018 № 7-12/т карарына 1 нче кушымта

Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә даими ташуларның муниципаль маршрутлары буенча пассажирларны һәм багажны автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты белән даими ташуларга чик дәрәҗә максималь тарифлар

| Транспорт төре | Бер мәртәбә бару һәм бер урынга исәпләнгән багажны алып бару өчен чик дәрәҗәдәге максималь тарифлар (сум) | | |
|---|---|---|---|
| | билетны транспорт салонында сатып алганда | юл өчен озак файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә | |
| | | 1 мәртәбә барган өчен[1] | 100 мәртәбә барган өчен[2] |
| автобус | 27 | 25 | 18 |
| Троллейбус | 27 | 25 | 18 |
| Трамвай | 27 | 25 | 18 |

<1> шәһәр юнәлешендә барганда, төгәл сумма чикләрендә бару хокукын бирә торган, озак файдаланылучы билет ярдәмендә түләгәндә;

<2> юл өчен күрсәтелгән вакыт чорында шәһәр буенча билгеле күләмдә юлда йөрү хокукын бирүче, озак файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә.

Искәрмә. Багажны алып бару бәясен түләү юл бәясен түләүдән аерым гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.12.2018 № 7-12/т карарына 2 нче кушымта

## Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә пассажирларны һәм багаж ташуларга чик дәрәҗә максималь тарифлар

| Транспорт төре | Бер мәртәбә бару һәм бер урынга исәпләнгән багажны алып бару өчен чик дәрәҗәдәге максималь тарифлар (сум) | | |
|---|---|---|---|
| | метрополитен кассаларында жетон сатып алганда | юл өчен озак файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә | |
| | | 1 мәртәбә барган өчен[1] | 100 мәртәбә барган өчен[2] |
| Метрополитен | 27 | 25 | 18 |

<1> шәһәр юнәлешендә барганда, төгәл сумма чикләрендә бару хокукын бирә торган, озак файдаланылучы билет ярдәмендә түләгәндә;

<2> юл өчен күрсәтелгән вакыт чорында шәһәр буенча билгеле күләмдә юлда йөрү хокукын бирүче, озак файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә.

Искәрмә. Багажны алып бару бәясен түләү юл бәясен түләүдән аерым гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге